2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авылы җирлеге Елховой авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү; территорияне төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү; төзекләндерү, «Буровой» чишмәсе өчен насос будкасы сатып алу, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Елховой авылы, Совет урамы, 67 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Елховой авыл җирлеге башлыгы А.А. Хәсәншин